РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраль 2022г. г. Альметьевск № 63

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы «Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре җирле үзидарә органнары белән Әлмәт муниципаль районының 2017 елның 31 маендагы 82 номерлы карары белән расланган вәкаләтләрнең бер елешен тапшыру (кабул итү) турында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр тезү тәртибе нигезендә, «Региональ законнар Аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын «Кодекс» мәгълүмат системасын куллану практикасы темасы буенча видеоконференция режимындагы киңәшмә беркетмәсенең 3 пунктына таянып:

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2021 елның 28 сентябрендәге 47 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче кушымтаның 6 пунктындагы 3 абзацында «гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын үткәрү турында һәм аларны уздыруны оештыралар» сүзләрен «гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу яисә килеп чыгу куркынычы булганда эвакуация чараларын оештыралар һәм уздыралар» сүзләренә алмаштырырга;

Зак. № 1352-200

1.2. 1 нче кушымтаның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 абзац өстәргә: «- федераль, төбәкара, төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә Россия Федерациясе гражданнарының, чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның гадәттән тыш хәл зонасында булган торак урыннарында яшәү фактларын, аларның тормыш-көнкүреше шартларын бозу һәм гадәттән тыш хәл аркасында алар тарафыннан мөлкәт югалту очракларын билгеле.»;

1.3 нче кушымтаның 32 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Федераль закон нигезендә шәһәр ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү:».

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник»» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO. TATARSTAN.RU) һәм һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча (Мусин Р.Ф.), торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү мәсьәләләре буенча (Зотов Ю.И.) даими комиссияләренә йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ» Т.Д. Нагуманов